| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>НАДЕЖДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НАДЕЖДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 ноябрь, 2023 ел Надеждино авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Морат авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 22 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Морат авылы, Мәктәп урамы, 15 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Морат торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның **беренче этабын** билгеләргә.
2. 2023 елның 24 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Морат авылы, Луговая урамы, 10 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Морат торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның **икенче этабын** билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Морат авыл җирлеге Надеждино авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева